| ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

3 д. им. М. Вахитова 05.11.2025

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Бакча Сарай авылында үзара салым кертү һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына 22.11.2013 ел № 909 (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан районы Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай бистәсендә гражданнар арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыенны 2025 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Бакча-Сарай Бистәсе, Яшьләр урамы, 2б адресы буенча, авыл клубы бинасында билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенеңБакча Сарай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бакча-Сарай Бистәсе балалар мәйданчыгы территориясендә видеокүзәтү камералары урнаштыру):

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Каримов